РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_12_» __ноябрь_ 2024 ел №_275__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләренең түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә, Югары Кәминкә, Ивашкино, Кармыш, Күтәмә, Лашман, Мордва Афонькәсе, Түбән Кәминкә, Түбән Кармалка, Яңа Элмәле, Яңа Кади, Иске Кади, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Туймәт, Ульяновка, Шешминка авыл җирлекләре вәкиллекле органнарының тәкъдимен кабул итәргә:

- мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү (скважиналар, су җыю манаралары, сууткәргеч челтәрләр), шул исәптән муниципаль милектәге һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү, мөлкәт белән идарә итү һәм контрольдә тоту, шул исәптән муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән, шул исәптән:

а) муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү буенча муниципаль мөлкәтне оператив идарә итү (хуҗалык алып бару) хокукында муниципаль учреждениеләргә (предприятиеләргә) беркетү турында хокукый актлар чыгару (кабул итү) ;

- тартып алу, сату;

- аренда түләвен билгеләү, аның күләмен үзгәртү турында; арендага бирү турында (шул исәптән муниципаль преференцияләр бирү турында);

- мөлкәтне файдалануга тапшыру турында; Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә мөлкәт белән идарә итүгә һәм аның белән эш итүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча милеккә бирү турында, шул исәптән судларда, контроль (күзәтчелек) органнарында «Җирлек» мәнфәгатьләрен яклау турында;

б) муниципаль мөлкәткә карата Россия Федерациясе законнары нигезендә граждан-хокукый шартнамәләр төзү, шул исәптән аларны хокукый анализлауны һәм килештерүне, шулай ук шартнамәләр шартлары буенча фикер каршылыкларын җайга салу максатларында контрагентлар белән хат алышуны тәэмин итү;

в) мөлкәткә карата шартнамәләр буенча алынган акчаларны җирлек бюджетына күчерү;

г) муниципаль мөлкәтне федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру;

д) муниципаль милек объектларын хосусыйлаштыру документларын саклау;

е) муниципаль мөлкәтне сату, арендага бирү, файдалану, идарә итү буенча гамәлдәге законнар нигезендә аукционнар һәм конкурслар оештыру.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына:

- Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта нигезендә типлаштырылган форма нигезендә тапшыру турында килешүләр төзергә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешүне гамәлгә ашыру өчен норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар чыгарырга хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов